КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 41

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2015 ел, 29 гыйнвар, 48 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Дәүләт торак контроле органнарының Россия Федерациясе субъектында күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча эшчәнлеген тәэмин итү өчен лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе һәм аның эшчәнлеге турында методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2016 ел, 17 август, 570/б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2015 ел, 29 гыйнвар, 48 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 7 февраль, 69 нчы, 2016 ел, 28 октябрь, 793 нче, 2017 ел, 8 июнь, 357 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе хакында нигезләмәгә, 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«11. Лицензия комиссиясе өч ел вакытка төзелә. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң комиссия составы Лицензия комиссиясенең яңа составын раслый торган тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергәнгә кадәр лицензияләү буенча эшчәнлеген дәвам итә.».

2. Бу карарның көче 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин